**Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы ТатарТалкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Ялан авылы торак пункты гражданнары җыены турында**

**КАРАР**

2018елның 19 ноябре №1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы Татарстан Республикасының 35 нче маддәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча 2018 елның 19 ноябрендә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “Чистай муниципаль районы ТатарТалкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Ялан авылы торак пунктында Чистай муниципаль районы ТатарТалкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Ялан авылы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, 2019 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- бульдозер эшләре, Кызыл Ялан авылында авыл хуҗалыгы производствосы калдыкларын өю территорияләрен ишү һәм тыгызлап тигезләү;

- Кызыл Ялан авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (агымдагы һәм капиталь ремонт, вак таш сатып алу һәм китерү, вак таш җәю)

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнарның җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукы булган җыенда катнашучылар исемлегенә 227 гражданнар җыенында катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә 115 кеше катнашты.

Гражданнар җыенында катнашучыларның тавыш бирү нәтиҗәләре буенча тавышлар түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе буенча гражданнар җыенының 115 катнашучысы тавыш бирде;

«Юк» позициясе буенча гражданнар җыенының 0 катнашучысы тавыш бирде.

.

Алда язылганнар нигезендә гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Чистай муниципаль районы ТатарТалкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Ялан авылы торак пунктында гражданнар җыенын булды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.

2. “Чистай муниципаль районы ТатарТалкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Ялан авылы торак пунктында Чистай муниципаль районы ТатарТалкышы авыл җирлеге составына керүче Кызыл Ялан авылы торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала 2019 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле билгеләнештәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә Сез ризамы:

- бульдозер эшләре, Кызыл Ялан авылында авыл хуҗалыгы производствосы калдыкларын өю территорияләрен ишү һәм тыгызлап тигезләү;

- Кызыл Ялан авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау (агымдагы һәм капиталь ремонт, вак таш сатып алу һәм китерү, вак таш җәю) мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Чистай муниципаль районы ТатарТалкышы авыл җирлегенең Кызыл Ялан авылында гражданнар җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегендә яшәүчеләр күпләп җыела торган урыннарда, стендларга һәм белдерү такталарына элү юлы белән халыкка белдерергә, шулай ук Чистай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТатарТалкышы авыл җирлеге
башлыгы _________________ М.М. Валиев